КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 апрель г.Казань № 352

«Татарстан Республикасы Президенты Эшләр
идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны
комплексы» дәүләт бюджет учреждениесен
бетерү турында

Татарстан Республикасы бюджетын оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең 420111, Татарстан Республикасы, Казан ш., Батурин ур., 7А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба - Учреждение) бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә:

бетерү турында карар кабул итәргә;

Учреждениенең ликвидация комиссиясе составын расларга;

Учреждениене бетерү тәртибен һәм срокларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

Учреждениене бетерү турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Учреждениенең бетерү процессында булуы турындагы мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен терки торган органга бирергә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә бетерелә торган учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне, шулай ук күчемсез мөлкәт объектларына техник документацияне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә Учреждениене бетерү нәтиҗәсендә эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

Учреждениене бетерү буенча законнарда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе тәкъдим иткән исемлек нигезендә, элек Учреждениегә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен 60 көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин